| | |
|---|---|
| СОВЕТ БАЛТАСИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«02» март 2023ел. № 81

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында.**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 14.07.2022 ел, № 237-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Балтач шәһәр җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге Советының 23.04.2021 ел, №31 карары белән расланган түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 26 статьяның 3 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле пунктлар белән тулыландырырга:

«4) вакыты чиксез хезмәт көне өчен айлык өстәмә;

5) закон нигезендә эш бирүченең аерым күрсәтмәсе белән билгеләнә торган муниципаль хезмәткәрне акчалата тотуны тәшкил итүче башка өстәмә түләүләр».

1.2.31 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узу чорында хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен мәҗбүри пенсия иминияте һәм мәҗбүри социаль иминият системаларында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру;"

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы" интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач

муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (baltasi.tatarstan.ru).

3. Башкару контролен үземдә калдырам.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин